**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

---

2015елның 12 феврале 22№

# РАСПОРЯЖЕНИЕ
# БОЕРЫК

Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 1 февралендәге йөкләмәләрен үтәү йөзеннән һәм Әлки муниципаль районы икътисадының торышын тотрыкландыру максатларында:

1. 1 нче кушымта нигезендә Әлки муниципаль районының кризиска каршы штаб турындагы нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының 2015 елга хезмәт базарында кризиска каршы гамәлләр планын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Сәлахов Р.Р. йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: А.Ф. Никошин

Әлки районы Башкарма комитет
җитәкчесенең 2015 елның 12
февралендәге 22 номерлы
күрсәтмәсенә1 нче кушымта

Әлки муниципаль районының кризиска каршы тору штабы
турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кризиска каршы штаб (алга таба - штаб) җирле үзидарә органнары һәм башкарма хакимиятнең территориаль органнары, предприятиеләр, ибюджет учреждениеләре оешмалары арасында муниципаль берәмлектә финанс һәм икътисадый кризис нәтиҗәләрен йомшарту, икътисадның реаль секторының һәм социаль өлкәнең тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү һәм үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан төзелә.

1.2. Штаб үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, штаб эшчәнлеге өлкәсенә караган Татарстан Республикасы законнары, Әлки муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезлзмәгә таяна.

## 2. Штабның төп бурычлары һәм хокуклары

2.1 Штабның төп бурычлары:

- Әлки муниципаль районындагы социаль-икътисадый һәм финанс хәлен анализлау һәм бәяләү, финанс һәм икътисадый кризисның икътисадтагы, социаль өлкәдәге, Әлки муниципаль районының бюджет системасындагы вәзгыятькә потенциаль янауларын һәм мөмкин булган тискәре йогынтысын ачыклау;
- Әлки муниципаль районында финанс һәм икътисадый кризис нәтиҗәләрен йомшартуга юнәлтелгән чаралар эшләү.

2.2. Штаб хокуклы:

-билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының территориаль органнарыннан, коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалардан, предприятие һәм оешмалардан, милек хокукына бәйсез рәвештә, бюджет учреждениеләреннән, Әлки муниципаль районының иҗтимагый берләшмәләреннән кирәкле материаллар соратып алырга;

- федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар, предприятие һәм оешма вәкилләрен, милек хокукына бәйсез рәвештә, бюджет предприятие һәм оешмалары вәкилләрен, бюджет учреждениеләре, Әлки муниципаль районының иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен кризиска каршы штаб утырышларына чакырырга;

- федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, коммерциячел һәм коммерциягә

карамаган оешмаларга, предприятие һәм оешмаларга, милек хокукына бәйсез рәвештә, бюджет учреждениеләренә, Әлки муниципаль районының иҗтимагый берләшмәләренә тәкъдимнәр бирергә.

## 3. Эшне оештыру

3.1. Штаб составы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән раслана. Штаб составына штаб рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм штаб әгъзалары керә.

Штаб рәисе булып Әлки муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе тора.

3.2. Штабның эшчәнлеген тәэмин итәләр:

- Әлки муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге;
-Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасы;
тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия;
-башка кызыксынган оешма һәм ведомстволар.

3.3. Штаб утырышлары атна саен уздырыла.

3.4. Штаб утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча карарлар фикер алышу нәтиҗәләре буенча кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.5. Штаб карарлары Әлки муниципаль районының тиешле норматив хокукый актларын әзерләү өчен нигез булырга мөмкин.